ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 381 «31» 03 2017 ел

Шәһәр һәм район территорияләрен чистарту
буенча санитар- экологик икеайлык
игълан итү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 мартында кабул ителгән б527-р номерлы боерыгын үтәү һәм торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуны тәэмин итү һәм аларны халыкның экология һәм санитария эпидемиология иминлеге таләпләренә җавап бирә торган хәлгә китерүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2017 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр шәһәр һәм район торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгын игълан итәргә.

2. Мамадыш муниципаль район берәмлекләре башкарма комитетларына, Мамадыш шәһәре башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар чистарту планнарын әзерләүне һәм 2017 елның 1 апреленә кадәр раслауны;

- агачлар һәм куаклар утырту, юллар һәм тротуарлар, йортларның алгы якларын ремонтлау, урамнарны яктырту, зиратларны, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын төзекләндерү, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау һәм башкалар буенча биремнәр билгеләргә.;

- предприятие, учреждение, башка оешма һәм халык житәкчеләренә шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен төзекләндерү буенча язгы санитар чистарту турында мәгълүмат җиткерү;

- җирле халык һәм укучылар катнашында транспорт чараларын һәм предприятиеләрнең һәм оешмаларның юл-төзелеш механизмнарын җәлеп итеп торак пунктлар территорияләрен санитар чистарту буенча массакүләм өмәләрне

оештырырга;

- йорт хуҗалары территориясеннән көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны үз вакытында бетерүне тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрү, ведомство карамагына карамастан, сәнәгать предприятиеләре, төзелеш оешмалары, базарлар, дәвалау, сәүдә учреждениеләре һәм мәдәни-көнкүреш оешмалары;

- административ комиссиянең җирлек һәм шәһәр территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны көчәйтү өлешендә эшен активлаштырырга, шулай ук язгы санитар чистарту һәм төзекләндерү барышында шәһәр һәм районны контрольлек итүче органнар белән берлектә рейд тикшерүләрен оештырырга һәм үткәрергә;

- каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрүне;

- терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрүне;

- «Татарстан Республикасы Экологик картасы» геомәгълүмат системасы www.ecokarta.tatar.ru ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мониторингын гамәлгә ашыруны;

- эшсезлек буенча район үзәгендә учетта торучы эшсезләрне санитар-экологик чистарту эшенә җәлеп итү.

3.”ҖЧҖ Мамадыш ТКХ” оешмасына:

Каты көнкүреш калдыкларын аеру һәм күмүне , чүп чыгару өчен махсус машина паркы һәм чүп полигоннары эшен тиешенчә оештырыга тәкъдим итәргә;

4. “Экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиясенә “ Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Мамадыш районы һәм Мамадыш шәһәре буенча территориаль идарәсенә (Маснавиева М.Х.), Мамадыш районы һәм мамадыш шәһәре территориясендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә табигатьне саклау турындагы законнар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны тәкъдим итәргә;

5. Мамадыш муниципаль районының “Экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиясенә “ бу боерыкка теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча икеайлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны атна саен, пәнҗешәмбе,

2017 елның 13, 27 апрелендә, 11, 25 маенда бу боерыкка теркәлгән

2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча (аңлатма язуын теркәп) Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына кертүне.

6. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына икеайлык кысаларында үткәрелә торган эшне “Нократ” (“Вятка”) газетасында әледән-әле яктыртып торуны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар планы

| № п/п | Эшләрнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 01.04.2017 алып 31.05.2017 кадәрге чорга план |
|---|---|---|---|
| 1. | Катнашкан оешмалар һәм предприятиеләр саны, барлыгы: | бер. | 280 |
| | Шул исәптән ЖКХ | бер. | 1 |
| 2. | Якын-тирә территорияләрне җыештырырга: | | |
| | Йорт тирәсе | бер. | 128 |
| | Федераль юл М-7 | км | 44,4 |
| | территориаль әһәмияттәге юлларга | км | 334 |
| 3. | утыртырга: | | |
| | агачлар, куаклар | шт. | 1200 |
| | куаклар | шт. | 2800 |
| 4. | Санитар кисү | | |
| | агачлар | шт. | 1200 |
| | куаклар | шт. | 1500 |
| 5. | ремонтларга: | | |
| | Куркынычсызлык киртәләре | п.м | 1000 |
| | Йорт фасадлары | куб.м | 3000 |
| | Балалар мәйданчыгы | шт. | 15 |
| 6. | Урам яктырту баганаларын буяу | шт. | 3000 |
| 7. | ПГС һәм ком | куб.м | 500 |
| 8. | ТБО чыгару | куб.м | 5000 |
| 9. | спецавтотранспорт | шт. | 50 |
| 10. | Контейнерлар мәйданчыгы саны | шт. | 267 |
| | Шул исәптән яңалары | шт. | 6 |
| 11. | контейнер, бункер саны барлыгы: | шт. | 303 |
| | Шул исәптән: | | |
| | ремонтларга | шт. | 30 |
| | Яңаны алырга | шт. | 10 |
| 12. | Халык саны | чел. | 15000 |
| 13. | Биологик калдыкларны утильләштерү урыннарын төзекләндерү: | | |
| | Биотермик чокырлар | шт. | 30 |
| | Себер түләмәле хайваннарны күмү | шт. | 2 |

Территориаль үсеш бүлегенең
Әйдәп баручы консультанты В.И. Никитин